КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2024 ел, 7 март г.Казань № 6-487

Халыкка дәүләт сәясәте, Татарстан Республикасының социаль-икътисадый һәм мәдәни үсеше турында киң мәгълүмат бирү максатларында:

1. Республика башкарма хакимият органнарына ведомство буйсынуындагы оешмалар (мәгариф оешмаларын, сәламәтлек саклау оешмаларын, мәдәният оешмаларын кертеп) өчен, аларның юнәлешен исәпкә алып, 2024 елның икенче ярты еллыгына вакытлы матбугат басмаларына, шул исәптән «Российская газета», «Республика Татарстан», «Ватаным Татарстан» иҗтимагый-сәяси газеталарына, «Татарстан Республикасы законнар җыелмасы», «Казан утлары», «Татарстан» журналларына язылуны оештырырга һәм язылган басмалар санын 2023 елның икенче ярты еллыгына язылган басмалар саныннан ким булмаган күләмдә тәэмин итәргә.

2. Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре башлыкларына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

бюджет муниципаль учреждениеләре тарафыннан 2024 елның икенче ярты еллыгына язылу кампаниясе барышын тикшерүдә тотуны тәэмин итүне;

Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына 2024 елның 31 июленә кадәр язылу кампаниясе нәтиҗәләре турында хисап җибәрүне;

«Российская газета» газетасы редакциясенә, район, шәһәр газеталары һәм республика журналлары, шул исәптән «Татарстан Республикасы законнар җыелмасы», «Казан утлары», «Татарстан» журналлары редакцияләренә, «Республика Татарстан» газетасы редакциясе» һәм «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе» дәүләт бюджет учреждениеләренә вакытлы матбугат басмасын популярлаштыруга һәм аларга язылуны активлаштыруга булышлык күрсәтә торган чараларны үткәрүдә һәрьяклап ярдәм күрсәтүне.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына, «Татарстан почтасы» федераль почта элемтәсе идарәсе йөзендә «Россия почтасы» акционерлык җәмгыяте белән берлектә, 2024 елның 31 июленә кадәр:

Татарстан Республикасы шәһәрләре һәм районнары яктылыгында 2024 елның икенче ярты еллыгына язылу кампаниясе йомгаклары турындагы мәгълүматны «Ачык Татарстан» порталында урнаштырырга;

2024 елның икенче ярты еллыгына вакытлы матбугат басмаларына язылу кампаниясе йомгаклары турындагы мәгълүматны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

4. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына язылу кампаниясен массакүләм мәгълүмат чараларында киң яктыртуны оештырырга.

5. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин